ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 39-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 39-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2025 елның 20 феврале
№ 215-VII ДС

39-7 номерлы проект

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелә

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

**1 статья**

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 24 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 28 (I өлеш), № 45 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 3 өлешендә «төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда педагогик хезмәткәрләр әзерли торган документлар исемлегенә өстәмә рәвештә түбәндәге өстәмә исемлекне расларга хокуклы» сүзләрен «Федераль законның 47 статьясындагы $6^1$ өлешендәге 1 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә өстәмә рәвештә төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда педагогик хезмәткәрләр әзерли торган өстәмә документлар исемлеген расларга хокуклы» сүзләренә алмаштырырга;

2) 15 статьяда:
а) исемдә «, инвалидларның (инвалид балаларның)» сүзләрен өстәргә;
б) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1. Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле белем алучыларга, инвалидларга (инвалид балаларга) белем бирүне һәм аларны тәрбияләүне оештыру шартлары психология-медицина-педагогика комиссиясе тәкъдимнәрендә, ә инвалидлар (инвалид балалар) өчен шулай ук инвалидны (инвалид баланы) индивидуаль реабилитацияләү һәм абилитацияләү программасы нигезендә билгеләнә.»;
в) 2 өлештә беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле белем алучыларга, инвалидларга (инвалид балаларга) гомуми белем бирү, психология-медицина-педагогика комиссиясе тәкъдимнәре

белән җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмаларда башкарыла.»;

г) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Әлеге Законда сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле белем алучыларның, инвалидларның (инвалид балаларның) белем алуы өчен махсус шартлар дигәндә, түбәндәгеләр аңлашыла:

1) белем бирү эчтәлеген адаптацияләүне тәэмин итә торган һәм мондый укучыларның психофизик үсеше үзенчәлекләрен һәм аларның сәламәтлеге торышын исәпкә ала торган җайлаштырылган белем бирү программаларын, укыту һәм тәрбияләү ысулларын һәм чараларын куллануны үз эченә алган белем бирү, тәрбияләү һәм үстерү шартлары;

2) төркемләп һәм индивидуаль коррекция дәресләре үткәрү;

3) махсус дәреслекләр, укыту ярдәмлекләре һәм дидактик материаллар, күмәк һәм индивидуаль кулланылыштагы махсус техник укыту чаралары белән тәэмин итү;

4) кирәкле техник ярдәм күрсәтүче ассистент (ярдәмче), рус ишарәләр теленнән тәрҗемәче (сурдотәрҗемәче, тифлосурдотәрҗемәче) хезмәтләрен күрсәтүне, шулай ук психология-медицина-педагогика комиссиясе тәкъдимнәре нигезендә педагогик хезмәткәрләр хезмәтләрен күрсәтүне тәэмин итү;

5) белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмалар бинасына кереп йөрүне тәэмин итү;

6) сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле белем алучыларның, инвалидларның (инвалид балаларның) алардан башка уку-укыту программаларын үзләштерүе мөмкин булмаган яисә кыенлаша торган башка шартлар.

д) 5 өлештә «акылга зәгыйф» сүзләрен «интеллектлары бозылган» сүзләренә, «катлаулы дефектлары булган» сүзләрен «үсешнең күп төрле авыр җитешсезлекләре булган» сүзләренә алмаштырырга;

е) 8 өлештә «акылга зәгыйфьлекнең төрле рәвешләрендә» сүзләрен «интеллектлары бозылган» сүзләренә алмаштырырга;

ж) 9 өлештә «, инвалидларның (инвалид балаларның)» сүзләрен өстәргә;

з) 10 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Татарстан Республикасы бюджеты ассигнованиеләре исәбеннән белем алучы сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле белем алучыларга, инвалидларга (инвалид балаларга) түләүсез махсус дәреслекләр, укыту ярдәмлекләре һәм дидактик материаллар, күмәк һәм индивидуаль кулланылыштагы махсус техник укыту чаралары, кирәкле техник ярдәм күрсәтүче ассистент (ярдәмче), рус ишарәләр теленнән тәрҗемәче (сурдотәрҗемәче, тифлосурдотәрҗемәче) хезмәтләре, шулай ук, федераль бюджетның бюджет ассигнованиеләре исәбеннән белем алучылардан тыш, психология-медицина-педагогика комиссиясе тәкъдимнәре нигезендә педагогик хезмәткәрләр хезмәтләре тәкъдим ителә.»;

и) 12 өлештә:

өченче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Белем бирүне өйдә оештыру өчен нигез булып ата-ананың (законлы вәкилләрнең) язма рәвештә мөрәҗәгате һәм сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә

ашыру, норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы билгеләгән тәртиптә балада сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру, норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан расланган төп гомуми белем бирү программалары буенча өйдә белем алуга хокук бирә торган авырулар исемлегенә кертелгән авыруның булуы турында медицина оешмасы тарафыннан бирелгән медицина бәяләмәсе тора.»;

түбәндәге эчтәлектәге җөмләне өстәргә: «Белем бирүне медицина оешмасында оештыру өчен нигез булып ата-ананың (законлы вәкилләрнең) язма мөрәҗәгате һәм сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру, норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы билгеләгән тәртиптә медицина оешмасы тарафыннан бирелгән, баланы махсуслаштырылган, шул исәптән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтелә торган медицина оешмасына госпитализацияләү фактын раслый торган белешмә тора.»;

3) 18 статьяның 2 өлешендә «сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле белем алучыларның» сүзләреннән соң «, инвалидларның (инвалид балаларның)» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон 2025 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектына**

**АҢЛАТМА**

Закон проекты «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законга 2024 елның 8 августындагы 315-ФЗ номерлы һәм 328-ФЗ номерлы федераль законнар белән кертелгән үзгәрешләргә бәйле рәвештә эшләнде.

2024 елның 8 августындагы 315-ФЗ номерлы Федераль закон белән белем алуны оештыруны хокукый җайга салу принципларын камилләштерүгә һәм сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән затларны, инвалидларны (инвалид балаларны) аларның психофизик үсешен һәм сәламәтлек торышын исәпкә алып укыту өчен махсус шартлар тудыруга юнәлдерелгән үзгәрешләр кертелде.

Аерым алганда, «катлаулы дефектлар» төшенчәсе «үсешнең күп төрле авыр җитешсезлекләре» төшенчәсе белән, «акылга зәгыйфь» төшенчәсе – «интеллект бозылу» төшенчәсе белән алмаштырылган, шулай итеп, алар укучыларны медицина диагнозы булу күзлегеннән түгел, ә педагогик характеристика күзлегеннән характерлый.

Мәгариф оешмаларына сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид укучыларга белем алу өчен, ә инвалидлык дәрәҗәсе булган укучылар өчен шулай ук аларның индивидуаль реабилитацияләү һәм абилитацияләү программасы нигезендә махсус шартлар тудыру бурычы йөкләнә.

Бер үк вакытта педагогларга укучыларның психофизик үсеш үзенчәлекләрен һәм аларның сәламәтлек торышын исәпкә алу, сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән укучыларга һәм инвалид укучыларга белем алу өчен кирәкле махсус шартларны үтәү бурычы йөкләнә.

Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән белем алучылар, инвалидлар (инвалид балалар) өчен махсус шартларның элек билгеләнгән гомуми категорияләре белән чагыштырганда белем алу өчен сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән белем алучыларга, инвалидларга алардан башка белем бирү программаларын үзләштерү мөмкин булмаган яисә кыенлаша торган махсус шартлар төрләре конкретлаштырылган.

2024 елның 8 августындагы 328-ФЗ номерлы Федераль закон белән «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 47 статьясындагы $6^1$ өлешендәге исемлекләрнең исемнәре төгәлләштерелә.

Закон проекты тарафыннан күрсәтелгән үзгәрешләр нигезендә республика законнарына корреспондентлык үзгәрешләре карала, шул исәптән сәламәтлеге буенча мәгариф оешмаларына йөри алмаган гомуми белем алучыларның өйдә яисә медицина оешмасында белем алуларын оештыру нигезләре һәм тәртибе төгәлләштерелә.

**«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары ИСЕМЛЕГЕ**

«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарларына үзгәрешләр кертү таләп ителәчәк:

«Татарстан Республикасы карамагындагы адаптацияләнгән төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар һәм шифаханә белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 8 апрелендәге 208 номерлы карар;

«Өйдә яки медицина оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирүне оештыру өлешендә озак вакыт дәвамында дәвалануга мохтаҗ белем алучыларның, шулай ук инвалид балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) һәм дәүләт яки муниципаль белем бирү оешмасы мөнәсәбәтләрен регламентлаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибен раслау турында» 2015 елның 4 мартындагы 135 номерлы карар;

«Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларын норматив финанслау турында» 2017 елның 8 августындагы 566 номерлы карар.

**«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектын ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар бүлеп бирүне таләп итми.